БАУЛЫ СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 Баулы шәһәре №40

Баулы муниципаль районы Советының
«Баулы муниципаль районы территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру
турында» 2021 елның 14 декабрендәге
93 номерлы карарына үзгәрешләр кертү
турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Баулы шәһәр прокуратурасының 2026 елның 1 апрелендәге 02-08-02-2026/Прдп 16-26-20920042 номерлы протесты нигезендә **КАРАР ИТТЕ**:

1. Баулы муниципаль район Советының «Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы карарына (11.04.2022 №111, 20.06.2023 №189, 26.10.2023 №224, 12.09.2024 № 267, 13.03.2025 № 298, 05.02.2026 №30 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәсендә:

3.4.2 пунктында “аларның вәкилләре” сүзләреннән соң, “шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша җибәрелгән” сүзләрен өстәргә;

3.4.2 пунктының 1) пунктчасында «видеоконференция элемтәсе аша» сүзләреннән соң «, «Инспектор» мобиль кушымтасын куллану,» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы карарына 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И.Гозәеров

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль район Советының
2021 елның 14 декабрендәге
93 номерлы карары белән

расланган

(Баулы муниципаль район Советының
2026 ел ____ __ номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның, Россия Федерациясе арбитраж суды тарафыннан энергия белән тәэмин итү (сатып алу-сату, электр энергиясе (куәте) белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү һәм (яки) кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү, су чыгару, газ белән тәэмин итү (шул исәптән баллоннарда көнкүреш газы белән тәэмин итү) килешүе буенча бурычларны түләтү турында дәгъва гаризасы (дәгъва гаризалары) кабул ителүе турында мәгълүматка ия булуы, күпфатирлы йортта милекчеләргә һәм кулланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәт күрсәтүне тәэмин итү һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту вакытында кулланылган коммуналь ресурсларны сатып алу максатында, каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү килешүе буенча, гомуми суммасы өч йөз мең сумнан артып киткән, карар кабул ителгән көнгә кадәр унике ай эчендә барлыкка килгән бурычлар турында мәгълүматка ия булуы.

2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан расланган куллану нормативыннан чыгып, җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү исәпләү турында белешмәләрнең рәттән өч хисап чорыннан артыграк булуы.